СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.12.2025 № 6/7

На №_________ от____________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җирлекләрнең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 пункты, Тукай муниципаль берәмлеге Советы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Әҗмәкәй, Бәтке, Биклән, Боерган, Борды, Иштирәк, Калмаш, Калмия, Князево, Комсомолец, Круглое Поле, Күзкәй, Кече Шилнә, Мәләкәс, Мусабай-Завод, Түбән Суыксу, Яңа Троицкий, Сәмәкәй, Иске Абдул, Иске Дөреш, Теләнче-Тамак, Шилнәбаш, Яңа Буләк авыл җирлекләре вәкиллекле органнарының Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына күрсәтелгән җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

- кышкы чорда җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына Тукай муниципаль районы җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә.

3. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнары, үз компетенциясе чикләрендә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән Килешүне гамәлгә ашыру өчен, норматив һәм норматив булмаган хокукый актлар чыгарырга хокуклы, дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Тукай муниципаль районының мәгълүмат сайтында (https://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе К.Р. Нәҗмиев